совершенствуется уже в силу специфики тренировки и соревнований. Однако учебно-тренировочный процесс превращается в средство нравственного воспитания лишь в том случае, когда перед юными борцами ставятся общественно полезные цели и они стимулируются к достижению этих целей через постепенное и последовательное преодоление трудностей.

Формирование нравственного сознания и самосознания у юных борцов взаимосвязано с воспитанием у них нравственных чувств. Необходимо использовать различные условия спортивной деятельности, а также ситуации, которые способствуют воспитанию моральных и гражданских чувств: патриотизма, товарищества, чувства соперничества, спортивной чести, спортивного долга и ответственности перед Родиной, спортивным коллективом, общественностью, самим собой.

**Насибуллова Г.Р.**

## ПОЭЗИЯНЕ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан шәһәре*

Поэтик әсәр тәрҗемәсе – әдәби тәрҗемәнең аеруча үзенчәлекле төре. “Шигырьне тәрҗемә итү, беренче чиратта, аның үзенчәлекләренә бәйле. Шигъри әсәр теленең авазлары билгеле бер тәртипкә китерелгән, поэзиядә бер генә сүз дә очраклы түгел. Шигырьдәге һәрбер лексик берәмлек шагыйрь өчен поэтик тема, сәнгати тәэсир итүнең үзенчәлекле алымы булырга мөмкин” [1, 148 б.]. Шуңа күрә шигъри әсәрне тәрҗемә итүчегә бик күп кыенлыклар белән очрашырга туры килә. Әлеге мәкаләдә без Г.Тукайның балалар өчен язылган шигырьләрдән төзелгән “Тылсымлы сәхифәләр” җыентыгына кертелгән тәрҗемәләрнең кайбер үзенчәлекләрен, тәрҗемәче каршында туган кайбер кыенлыкларны ачыкларга тырышырбыз. Г.Тукайның әдәби мирасын башка халыкларга җиткерүдә журналист, шагыйрь, тәрҗемәче Равил Бохараев зур хезмәт башкарды. “Тылсымлы сәхифәләр” җыентыгында Г.Тукайның шигырьләр татар, рус, инглиз телендә бирелгән. Әлеге җыентыкның тагын бер үзенчәлеге – бу шигырьләр буенча “Татармультфильм” оешмасы тарафыннан балалар өчен өч телдә мультфильмнар да төшерелгән. Тупланмадагы шигырьләрне инглиз теленә Илл Генн, Равил Бохараев һәм Азат Ганиев тәрҗемә иткән.

Шигъри әсәрне тәрҗемә итү – катлаулы процесс. Биредә тәрҗемәче алдына милли үзенчәлекне саклап калу, әсәр язылган чор рухын дөрес чагылдыру, төгәллек һәм тәрҗемәнең матурлыгы арасында сайлау кебек кыенлыклар белән очраша.

Поэзиягә шигырь төзелеше законнарына нигезләнгән билгеле бер ритм хас. Шигырь интонациясенә музыкальлек хас, ләкин шигырьнең музыкасы гадәти музыкадан нык аерыла. Шигырьнең музыкасы авазлар яңгырашыннан гына тумый, ул авазлар һәм мәгънәнең бердәмлегеннән барлыкка килә.





Шигъри әсәрдә синтаксик конструкцияләр дә поэтик максатка хезмәт итә. Г.Тукай шигъриятендә әлеге алым аша сәнгати югарылыкка ирешү аеруча чагылыш таба. Аның әсәрләре музыкаль, эчке ритмга ия. Татар һәм инглиз телләре синтаксисы бер-берсеннән бик нык аерыла. Шуңа күрә күп тәрҗемәләрдә җөмлә төзелешләре аша белдерелгән эчке ритм сакланып калмаган. Мәсәлән, Г.Тукайның “Иртә” шигырен алыйк:

Иртә. Дөнья җанлана
Мәшрикъ ягы аллана;
Кояш чыгып, нурлары
Төшеп җиргә ялгана.

Шагыйрьнең бу шигырендә атау җөмләләр, составында җыйнак гади җөмләләр булган тезмә кушма җөмләләрдән тора. Шулай ук әсәрдә сүзләрне кире тәртиптә бирү, инверсия куллану да еш очрый. “Иртә” шигыренең музыкальлеген охшаш авазларның кабатлануы да тәэмин итә. Шигырьдә [р], [н], [л] авазларының еш кабатлануы, әйтелеш ягыннан охшаш сүзләрнең санап кителүе аны эчке ритмга сала. Инглиз телендәге вариантта әлеге җыйнаклык, төзеклек, музыкальлек сакланып калмаган.

At dawn the world awakens, and
The East inflames and goes red,
The Sun comes out and its beams
Fall down to warm up the land.

Биредә “Иртә.” җөмләсе инглиз теле вариантында төшерелеп калдырыла. Аның мәгънәсе алдагы җөмләдә “at dawn” гыйбарәсе белән белдерелә. Бу очракта тәрҗемәче шагыйрьнең фикерен төгәллек кертеп тәрҗемә итә – “dawn” сүзе инглиз телендә кояш чыгуны аңлата.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, әсәр язылган вакытны башка телдә чагылдыру тәрҗемәче өчен төп проблемаларның берсе булып тора. Билгеле бер чорның теле тарихи һәм иҗтимагый вәзгыятьне чагылдыра. Чынлап та, вакыт факторы әсәрнең төп тукымасын тәшкил итә һәм ул тәрҗемәдә сакланырга тиеш. Биредә тәрҗемәчегә заман укучысы ихтыяҗларын да канәгатьләндерергә туры килә. Ләкин бу аның тәрҗемәсе “заманчалашырга” тиеш дигән сүз түгел. Шул ук вакытта ул укучы шул чор рухын тоярлык атмосфера тудырырга тиеш. Дөрес, Г.Тукай шигърияте бүгенге заман укучысы өчен дә актуаль яңгырый. Шул ук вакытта шагыйрьнең теле, сүзсурәте үзе яшәгән чорга алып кайта. Аның әсәрләрендә архаик сүзләр, формалар, җөмлә төзелешләре, XX гасыр башында киң кулланылышта булган гарәп-фарсы алынмалары еш очрый. Әлеге җәһәттән фәндә бик күп тикшеренүләр бар. Без бу өлкәгә киң тукталмыйча, тәрҗемәләрдә очраган кайбер архаизм үрнәкләрен карап үтәрбез. “Тылсымлы сәхифәләр” җыентыгына тупланган тәрҗемәләрдә архаизмнар күп очракта гадиләштерелеп, хәзерге заман укучысына яраклаштырылып бирелә. Күрәсең, тәрҗемәче шигырьләрнең балаларга юнәлтелгәнлеген дә истә тоткандыр. Мәсәлән, “Сөткә төшкән тычкан” шигырендә “ит гайрәт, сөбат” инглиз теленә “don't forget your goul” дип тәрҗемә ителә. Әлеге гыйбарә инглиз теленнән тәр-

жемә иткәндә “максатыңны онытма” дигәнне аңлата. “И карендәш!” эндәш сүзе “My dearest one!” дип бирелә. Карендәш дип татарларда туганга, бер милләттән булган кешегә эндәшәләр. Тәрҗемәче аны гадиләштереп “My dearest one!” – “Минем якын кешем!” дип бирә.

“Иртә” шигыреннән архаизмнарны тәрҗемә итүгә тагын бер мисал карап үтик:

Шушы вакытта балалар
Мәктәпкә таба баралар;
Букчалары артында,
Алар гыйлем дәртендә.

Инглиз телендә:

And children in the morning chill
Are off to school after the meal,
With full schoolbags at their backs,
They go to learn with hope and zeal.

Бирелдә “гыйлем дәртендә” гыйбарәсе укучыга ачыклабрак бирелә “They go to learn with hope and zeal”, ягъни алар тырышып һәм бик теләп укырга баралар.

Ике телне берничек тә тәнгәлләштереп булмый. Һәр сүзнең, гыйбарәнең, төшенчәнең төп-төгәл эквивалентын тәрҗемә телдә туры китерү мөмкин түгел. Шуңа күрә тәрҗемә процессында югары камиллеккә ирешү өчен тәрҗемәче төрле лексик һәм грамматик чаралар куллана. Аларны лексик-грамматик трансформацияләр дип атыйлар. Г.Тукай шигырьләре тәрҗемәләрендә төрле лексик трансформацияләр кулланылган. Тәрҗемәчеләр күп очракта конкретлаштыру, өстәлмәләр кертү алымнарын файдаланалар. Мәсәлән, “Иртә” шигырендәге “букчалары артында” дигән сүзтезмәне тәрҗемәче инглиз телендә тулыландырып “full schoolbags”, ягъни тулы букчалары дип бирә.

Шушы вакыт балалар
Мәктәп таба баралар;

инглиз телендә:

And children in the morning chill
Are off to school after the meal,

Г.Тукайны әлеге шигырь юллары инглиз телендә Балалар иртән мәктәпкә иртәнге аштан соң баралар дип тәрҗемә итәлә. Тәрҗемәче эчтәлекне бирү һәм рифма булдыру өчен үзеннән бик күп өстәлмәләр кертә. Бу алым аңа инглиз телендә камил шигырь тудыру өчен ярдәм итсә дә, чыганак тексттан ераклаштыра. Әлеге үзенчәлек “Бала белән күбәләк” шигырендә дә чагылыш таба. Инглиз телендә “Күбәләк” “Tiny little Butterfly” дип бирелә, ягъни бик кечкенә күбәләк дигәнне аңлата.

Тәрҗемәләрдә конкретлаштыру да еш очрый. Мәсәлән, “Күп очып армыйсың син ничек?” инглиз теленә “Flying since the crack of dawn” (иртә таңнан бирле очып) дип тәрҗемә итәлә.





Метафораларны тәрҗемә итү дә тәрҗемәчедән зур осталык, ике телне дә камил белүне таләп итә. Мәсәлән, Г.Тукайның “Сөткә төшкән тычкан” шигырендә “идән асты кошы – тычкан” инглиз теленә “a little caged mouse” дип тәрҗемә ителгән. Әлеге гыйбарә читлектәге тычкан дигән мәгънәне аңлата. Г.Тукайда тычкан, киресенчә, ирекле җанвар кебек күзаллана. Кайбер очракта тәрҗемәче, киресенчә, инглиз теленә генә хас булган метафора куллана. Мәсәлән, “Иртә” шигырендә “Көтү-көтү менмәктә күккә җитез кошлар да” инглиз телендә “The birds in flock into the sky take wing for the Almighty's sake” дип тәрҗемә итәлә. “For the Almighty's sake” дигән гыйбарә Аллаһы тәгалә янына (катына) дигәнне аңлата.

Һәрбер тәрҗемә югалтуга барып тоташа, әлеге югалту я формага, я эчтәлеккә тәэсир итмичә калмый. Г.Тукай шигырьләренең инглиз теленә тәрҗемәләреннән күренгәнчә, тәрҗемәчеләр эчтәлекне саклап калырга тырышканнар, күп очракта чит ил укучысы өчен аны тулыландырып та биргәннәр, төрле алымнар кулланып, татар теленең үзенчәлекләрен саклап калырга һәм башка телдә чагылдырырга тырышканнар. Әлеге тәрҗемәләр Г.Тукайның киңкырлы һәм бай иҗаты белән чит ил укучысына да танышырга мөмкинлек бирә.

*Әдәбият*

1. Науменко О.В. Особенности перевода поэзии // Сборник статей «Актуальные вопросы переводоведения и практики перевода» – г. Н.Новгород: Альба. – С. 147-151.
2. Тукай Г. Тылсымлы сәхифәләр – Казан: Промполиграф, 2011. - 41 б.
3. Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. – I т.

**Салахов Р.Ф., Салахова Р.И., Насибуллов Р.Р.**

## ЭСТЕТИЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ ДЕТЕЙ С ОГРАНИЧЕННЫМИ ВОЗМОЖНОСТЯМИ ЗДОРОВЬЯ СРЕДСТВАМИ ХУДОЖЕСТВЕННО-КОМПЬЮТЕРНОЙ ГРАФИКИ

*ФГАОУ ВО «Казанский (Приволжский) федеральный университет», г. Казань*

Сегодня для России характерным является развитие процессов гуманизации социальных отношений, переход к принципу социальной толерантности, признание и уважение прав и достоинства каждого человека независимо от его возможностей или убеждений. Современное культурно-образовательное пространство нацелено в первую очередь на формирование интеллекта личности, в то время как процессы эмоционально-духовного развития личности остаются на периферии педагогического воздействия.

Большое значение в осуществлении данного процесса имеет искусство. Адаптационные возможности искусства по отношению к ребенку с ограниченными возможностями здоровья связаны с тем, что оно является источником новых позитивных переживаний, содействует реализации его креативных потребностей, предоставляет ему неограниченные возможности